- Гасырлардан килгән хәзинә.

# Китап - белем чишмәсе

- Эпиграф итеп нәрсә алынган?
- Ни өчен шулай әйтелгән?


**Ребус чишәбез.**

,  ,укый (Нәкый)

исәнме” ,,әйбәт (Исәнбәт)


# Нәкый Исәнбәт иҗаты

















Нәкый Исәнбәт 1900нчы елның 10нчы гыйнварында Башкортстанның Салават районы Малаяз авылында мулла гаиләсендә туган.

Аның туган авылы мәңге яшел чыршылар, наратлар белән бизәлгән Урал итәгенә урнашкан. Шунда ул башлангыч белемне ала. 1910нчы елдан Уфада «Хөсәения» һәм «Галия» мәдрәсәләрендә укый.

- **Балачакта әсәрләрне яратып, кат-кат укый торган булган. Озакламый Нәкый үзе дә шигырьләр яза башлый. «Шүрәле» исемле беренче шигырен язганда, аңа ун гына яшь була.**
- **Унике яшеннән башлап, ул дәфтәренә мәкальләр, әйтемнәр, табышмаклар җыя башлый. Нәкый Исәнбәт мәктәпләрдә укытучы булып эшли һәм халык авыз иҗаты белән мавыга.**

# Гомере буе туплаган халык авыз иҗаты әсәрләрен аерым җыентыклар рәвешендә бастырып чыгара:
# «Татар халык мәкальләре» (өч томда),
# «Табышмаклар»,
# «Балалар фольклоры».






- Нәкый Исәнбәт  - тел галиме. Күп еллар дәвамында татар теленең фразеологик байлыгын җыйнап сүзлек итеп бастыра.



**Анының «*Уракчы кыз*»,**

**«*Бормалы су*», «*Гармунчы егет*»,**

**«*Син сазыңны уйнадың*» кебек күп кенә шигырьләре җыр булып яңгырый.**

**Нәкый Исәнбәт – драматург та.**

**Ул күпсанлы драма әсәрләрендә халыкның тарихын, гореф-гадәтләрен тирәннән сурәтли: *«Хуҗа Насретдин»*, *«Гөлҗамал»*, *«Мулланур Вахитов»*, *«Муса Җәлил»* әсәрләре шундыйлар.**

- **Ул оста тәрҗемәче буларак та танылды, Пушкин, Шекспир һ.б. әсәрләрен татарчага тәрҗемә итте.**

- **Татар әдәбияты, мәдәнияте һәм сәнгате өлкәсендәге игелекле хезмәтләре өчен Нәкый Исәнбәткә** ***Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге һәм Татарстанның Халык язучысы*** **дигән исем бирелде.**

- **Татар халкының рухи тормышында, сәнгать һәм әдәбиятында Нәкый Исәнбәт иҗаты күренекле урын алып тора. Өлкән язучыбыз Нәкый Исәнбәт 1992нче елны Казанда вафат була.**

Унөченче апрель.
Нәкый Исәнбәт иҗаты..

***маҗара*** *- приключение*
***дәвер, гасыр –*** *эпоха, век*
***көрәштәш –*** *соратник*
***рухи мирас –*** *духовное наследие*
***чагылыш –*** *отражение*

# Сораулар:

- **Нәкый Исәнбәт нинди әсәрләр язган?**
- **Анын нинди хезмәтләре бар?**

***Нәкый Исәнбәт иҗаты.***

- ***Мин бүген дәрестә ... өйрәндем.***
- ***Кызыклы булды: ...***
- ***Авыр булды: ...***
- ***Мине гаҗәпләндерде: ...***
- ***Мин белдем: ...***
- ***Мин ... билгесенә лаек.***

## Өй эше (сайлап алырга):


**1. Язучы Нәкый Исәнбәтнең тормышы һәм иҗаты турында сөйләргә.**

**2. Язучы турында өстәмә мәгълүматлар әзерләргә.**

**3. Н.Исәнбәтнең әсәрләренең, хезмәтләренең исемнәрен дәфтәргә язып куярга.**






Нәкый
Исәнбәт -
зур шәхес



БАЛАЛАР ФОЛЬКЛОРЫ


Н. ИСӘНБӘТ
ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ФРАЗЕОЛОГИК СҮЗЛЕГЕ
Н. ИСӘНБӘТ
ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ФРАЗЕОЛОГИК СҮЗЛЕГЕ


ТАТАР ХАЛЫК ИҖАТЫ
ХРЕСТОМАТИЯ
Нәкый Исәнбәт
НӘКЫЙ ИСӘНБӘТ
САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР


Татар халык мәкальләре
Татар халык мәкальләре
Татар халык мәкальләре


НӘКЫЙ ИСӘНБӘТ
НӘКЫЙ ИСӘНБӘТ


ТАТАР ХАЛЫК ТАБЫШ-МАКЛАРЫ